СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«25» февраль 2022 ел** **№ 41**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 03 декабрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлайавыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлайавыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 03.12.2021 ел, № 37 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 190 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннардан алынган продуктларның ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, әйләнә-тирә мохитне хайваннардан алынган калдыклар белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактик чаралар үткәрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров